Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Мөслим балалар сәнгать мәктәбе

# БӨЕК ҖИҢҮГӘ – 75 ЕЛ

***Бөек Җиңүнең 75 еллыгына багышланган әдәби-музыкаль кичә***




**Төзүчесе:** ***Мөслим балалар сәнгать мәктәбенең югары категорияле укытучысы Юсупова Г.М.***

**2020 нче ел**

# Аңлатма язуы

Бөек Җиңүнең 75 еллыгына багышлап үткәрелгән әлеге чара Бөек Ватан сугышы елларында халкыбызның фронтта һәм тылда күрсәткән тиңдәшсез батырлыгы үрнәкләре белән яшь буынны таныштыру; бүгенге тыныч тормышыбызны, бәхетле балачагыбызны  төшенергә ярдәм итү; буыннар арасындагы бәйләнешне ныгыту, яшьләр күңелендәге сугыш чорын, намуслы хезмәт белән көн күргән сугыш һәм тыл ветераннарына, апаларга, әбиләргә, тыл ветераннарына олы хөрмәт хисе тәрбияләү, гадел, тату, эшчән, игелекле булырга омтылыш уяту Ватанны ярату хисләре тәрбияләү максатын күздә тота.

Бөек Ватан сугышы чорында аерым урын алган этапларның барсында да районыбыз җирлегеннән киткән якташларыбызның кемнәредер катнашкан. Батырлык күрсәткән, канын түкән, гомерен  җәлләмәгән. Исән кайтканнары җиң сызганып илне торгызуда хезмәт куйган. Тылда хатын – кызлар, үсмерләр, олы яшьтәге  әби –бабаларыбыз төнне көнгә ялгап, көч җитмәслек эш башкарган. Бу кичә хәзерге чор балаларыннан  аларга ихтирам, хөрмәт, рәхмәт йөзеннән онытылмаслык булып истә калырлык чара булып узсын, дигән теләк белән төзелә...

**Максат:** Бөек Җиңүнең 75 еллыгына багышланган әдәби кичә аша яшь буынга шигырьләр, әдәби әсәрләр аша патриотик тәрбия бирү, сугыш чоры кешеләренең җиңүгә булган ышанычын, батырлыгын, рухи ныклыгын аңлату, фронтовик язучы – шагыйрьләр, авылдашларның Бөек Ватан сугышы елларында күрсәткән батырлыклары, тырыш хезмәтләре белән таныштыру, сугыш һәм тыл ветераннарына олы хөрмәт уяту, кешеләрне хөрмәт итү хисе тәрбияләү.

**Җиһазлау.** Сугыш чоры, сугыштан соң чоргы  җырлар аудиоязмалары (диск), кыр кухнясы, «Хәтер китабы», сугыш чоры плакатлары, стенгазеталар, күргәзмәләр, открыткалар, шарлар, чәчәкләр һ.б.; компьютер, проектор, экран, «Бөек Ватан сугышы», «Изге сугыш» клиплары,

«Нәсыйфулла Хәйруллин» «Сугышка озату», «Гармунчы солдатлар», «Гүзәл затлар һәм балалар», «Солдат хатлары» дигән рәсемнәр, фотосүрәтләр папкалары, «Җиңү көненә -75 ел» дигән темага презентация.

**Чара барышы.**

**Кунакларны каршы алу.**

Зифа Басыйрова исемендәге Мөслим мәдәният йорты алдында сугыш еллары язмалары (махсус сайлап алынган сугыш чоры, сугыштан соң чоргы җырлар, көйләр, сугыш маршлары) яңгырый, ярминкә оештырыла, оештыручылар (солдат киемнәреннән) кунакларга кыр кухнясы: кайнар солдат боткасы, коймак белән чәй тәкъдим итә.

Мәдәният йорты фойесы бәйрәмчә бизәлгән. Сәнгать мәктәбенең тынлы уен кораллар оркестры сугыш тематикасына попурри белән тамашачыларны каршы ала. Гомуми белем бирү мәктәп укучыларының Бөек Ватан сугышы тематикасына, Җиңү көненә 75 ел тулу уңаеннан стенгазеталар, ветераннарга багышланган котлау открыткаларыннан күргәзмә. Шулай ук фотокүргәзмә, сугышка багышланган музей экспонатларыннан күргәзмә, сугышта катнашкан автор-геройларының китап күргәзмәсе һ.б.

Һәрбер кергән ветеранны (кунакларны) солдат, моряк яки башка төрле киемнән 10-11 сыйныф укучылары каршы алып кулдан ясалган истәлекле бүләкләр, кичәнең программасын тапшыра һәм тамаша залына озата. Сәхнә чәчәкләр, шарлар белән бәйрәмчә бизәлгән. Пәрдәләр ябылган. Бары тик проектор гына пәрдәгә « Бөек Җиңүгә – 75 ел» – дип яктырта. Тамашачылар залда урыннарына урнашуга **экранда Бөек Ватан сугышына багышланган видеоклип күрсәтелә.**

Җыр бетүгә экран сүнә. ( Пәрдә ачыла) . Караңгы сәхнәдә катнашучылар пәйдә була, аларның чыгышы моңсу көй белән үрелеп бара. Биючеләр гади крестьян, эшче, солдат, табиб, медсестра, укытучы һ.б. образында тамашачыларга аркалары белән торалар, кулларында шәмнәр. Алып баручының беренче сүзләрендә күренмиләр, алып баручы һәрберсе

турында сөйли башлагач образлар бию хәрәкәтләре ясап бер-бер артлы борылалар прожектор һәрберсен аерым яктырта башлый.

**Сәхнә артыннан сөйлиләр: (төрле ир-егет, хатын –кыз тавышлары)**

1. Минем шундый нык яшисе килә иде!… Тагын бераз укысам мин доктор булыр идем…

2. Безнең авылыбызда башлангыч сыйныф укытучыларына кытлык булганга, мин укытучы булырга хыяллана идем …

3. Ә мин тиздән әти булырга җыена идем… Эх, баламны кочагыма алып, күкрәгемә кысасы иде!…

4. Ә мин өй салып гаиләм белән башка чыгарга уйлаган идем…

- Без, сугышта һәлак булучылар… (караңгылыкта шәмнәрнең бер өлеше яна)

- Без, концлагерьләрдә тилмереп үлүчеләр… (караңгылыкта шәмнәрнең икенче өлеше яна)

- Без, оккупациядә үлүчеләр…

(караңгылыкта шәмнәрнең өченче өлеше яна)

- Без, ачлыктан тилмереп үлүчеләр…

(караңгылыкта шәмнәрнең дүртенче өлеше яна һәм шәмнәрдән 75 саны ясалып яктыртыла). Образлар салмак көй астында караңгылыкта юкка чыга, 75 саны экранга күчә – **Бөек Җиңүгә – 75 ел**.

**Талмак кына көй. Алып баручы тавышы (сәхнә артында**):

Юк шул, хыяллар бары тик хыял гына… Укып та бетерә алмадылар, хыялларын тормышка ашырып матур өйләр салып, улларын- кызларын сөеп-назга күмә дә алмадылар… Балалары да әтием-әнием дип аларга эндәшә алмады… **Образлар шәмнәрен сүндереп караңгылыкта юкка чыга, пәрдәләр ябыла. Сәхнә яктыртыла.**

**«Һәрвакыт булсын кояш!»** (Л.Ошанин сүзләре, А.Островский музыкасы, Л.Айтуганов тәрҗемәсе) дигән җыр астында кечкенә балалар

шарлар һәм чәчәкләр тотып залга төрле яклардан керәләр, бииләр. (Бию ахырында ветераннарга үзләре әзерләгән бүләкләрен тапшыралар).

**Пәрдәләр ачыла. Сәхнәдә һәм экранда өй күренеше, гаилә** (бабай, әби, әни, әти, 5-6 яшьлек бала (кызлары)) өстәл артында урнашкан, гәҗит укып утыралар. Гәҗитне бала алып кергән, Бөек Җиңүнең 75 еллыгына багышланган «Авыл утлары» гәҗите, мәкаләнең берсендә баланың карт бабасы турында язылган. **Экранда** зур планда аерым «Авыл утлары» гәҗитендә Бөек Җиңүнең 75 еллыгына, сугыш ветераннарына багышлап язылган мәкаләләр, аларның фотосүрәтләре. Шул ук вакытта экран белән берлектә сәхнәдә дә күренеш бара.

**Бала.** Әти, әти, без бүген балалар мәйданчыгына барабызмы, минем атынасым килә?

**Әти.** Ашыкмале, кызым, тыңла әле.

**Бала.** Нәрсә инде? Гел шулай булыр инде, бабам, бабам, ә син мине алып барасыңмы? Син нигә елыйсың? Ни булды сиңа? Бабай, эндәш инде...

**Бабай.** И, кызым, бу шатлык яшьләре генә, хәтеремә төшкән вакыйгаларны искә алып елыйм... күптән булган чорларны уйлап. Әтием турында язганнар гәҗиткә, синең карт бабаң Нәсыйфулла турында.

**Бала.** Карт бабам турында, чынлапмы? Әллә ул герой?

**Бабай.** Сугышта булган һәр кеше герой була ул, әйе, кызым, карт бабаң да сугыш батыры, әбисе оныгыбызга карт бабасының медальләрен күрсәт әле.

(әби оекбаш бәйләвеннән туктап, комодтан кадерләп кенә бер төргәкне алып, аны сүтеп эченнән медальләр ала).

**Бала.** Шундый күп бабамның медальләре, әнием укы әле миңа да карт бабам турында...

(әнисе кыскача гына бабаларының батырлыкларын укый, экранда бабайның фотосүрәте – Нәсыйфулла Хәйруллин).

Хәйруллин Нәсыйфулла – олы тормыш юлы үткән шәхес. Ул 1921 нче елның гыйнварендә Тегермәнлек авылында туа.

19 яше тулуга ул Комсомольск шәһәрен төзүгә китә. Договор срогын тутырып туган төбәге – Тегермәнлек авылына кайта. Кайта да, хәрби хезмәткә алуларын сорап, 1940 елның көзендә Кытай чигендә 16 нчы армия составына кергән 17 танк дивизиясенең 33 нче полкында хезмәтен башлый. Сугыш башлануга аларның дивизиясен: «Минскины сакларга, немецларны кертмәскә!» - дигән әмер биреп юлга чыгаралар. Иң беренче чолганышта ук катлаулыклар килеп чыга: танкларда ягулык чамалы, салырга мөмкинлек юк, ватылганнары да бар, төзәтергә запчасть юк. Наганнан башка бер винтовка, бер граната да юк. Шулай бер тукталышта мотоколонна килүен хәбәр итәләр. Шул пистолет, наганнардан немецларны залп биреп каршылыйлар, берничә матайны тәгәрәтәләр…

Хәйруллин хезмәт иткән батальон тылны сакларга калдырыла. Июль азагында батальон Смоленскига да килеп җитә. Аннан егерме биш чакрым төньяктарак Кардым өчен сугышта Нәсыйфулла яралана. Днепр буеның Соловьев кичүендә фашист самолетларының һөҗүменнән соң ул кабат яралана. Аны Свердловск өлкәсе Кунара госпиталенә озаталар. Биш ай дәваланганнан соң, кабат стройга баса. Ләкин аны үз частенә җибәрмиләр: башта ул фронт өчен күләмле ярдәм күрсәтә, Красноярск депосы эшчеләре бронепоезд бүләк итә, Нәсыйфулла аларга булыша, аннары фронтка китә. Башта Мәскәү тирәләрендә, аннары Ленинградка таба җибәрәләр. Бологое станциясен дошманнан, аның авиациясеннән саклыйлар. Хөйруллин хезмәт иткән бронепоезд экипажына әледән – әле һөҗүм итеп торалар. Алган тән ярасы да үзен сиздереп тора. Кырык дүртенче елның август азакларында медкомиссия, мондый җәрәхәтләр белән сугышып йөрмиләр дип, аны кабат госпитальгә озата. Ул чакта Горький ( хәзер Түбән Новгород) шәһәрендә дәвалыйлар. Аннан чыккач солдат Хәйруллин Мәскәүдә 139 нчы Зенит артиллерия полкында сигезенче батареясенә хезмәт итәргә билгеләнә. Ул җиңүче гаскәрләр хөрмәтенә салют бирүче полк була. Салют бирү 1943нче елның 12 июленнән Орел һәм Белгород шәһәрләрен азат иткән көннән башлана. Ә Нәсыйфулла катнашында беренче залп 1945 нче елның 17

гыйнварендә  Польша башкаласы Варшаваны азат иткән көнне була. Барысы 89 тапкыр төрле әһәмияткә ия булган шәһәр һәм торак пунктларын азат иткән өчен яңгыраталар алар салют залпын. Соңгысы 90 нчысы – Җиңү салюты 356 тапкыр 1000 пушкадан бирелә. Салют пушкалары Мәскәү елгасы буенда Горький ял паркына урнаштырылган була, солдатлар да шунда ук землянкада яшиләр. Сугыш бетте дип, аларны кайтарырыга ашыкмыйлар, Мәскәү урамнарын чистарттыралар, чокырларны тигезләттерәләр, ватык җимерекләрне төзәттерәләр. Туган авылына кайту бәхетенә Насыйфулла 1946 нчы елның май уртасында гына ирешә.

Армиядән кайтуга ул колхозда атлар карый, бригадир, колхоз рәисе урынбасары, 2 ел колхоз рәисе  булып эшли. Белем күтәрү белән дә мәшгуль була һәм 25 ел дәвамында Вахитов исемендәге колхозның икътисадчысы булып эшли. «Атказанган колхозчы» исеменә лаек була, күп төрле Мактау кәгазьләре белән бүләкләнә…

**Бала.** (фотосүрәткә карап, карт бабасының медальләрен кулына тотып) - Карт бабам, кадерлем минем. Мин сине күрмәгән булсам да, батырлыгын белән горурланам. Вакытны кире кайтарып синең белән сөйләшергә иде, синең кочагыңа бер сыенырга иде...

**Пәрдә ябыла, ябык пәрдә алдына балалар чыга.**

**Җыр «Бабамның истәлекләре»** Лиана Әмирханова сүзләре, Тәлгать Вәлиев музыкасы. Башкара балалар ансамбле.

**Җырның соңгы 2 юлын җырлаганда:** Бабам үткән юллар буйлап сәяхәт кылам янә...  **Пәрдә ачыла. Шомлы көй яңгырый.**

**Алып баручы.** 1941 нче ел 22 июнь…**(Экранда һәм сәхнәдә табигать күренеше)**

1941 елның матур җәе иде... Чишмә буйларында уен-көлке, җыр-бию тавышлары яңгырап тора.. Сәхнәдә яшьләр. Башта кызлар, аннан соң егетләр бии башлый. Биюнең иң кызган чагында куркынган, дулкынланган кыяфәттә бер кыз йөгереп керә.

**Кыз.** Кызлар, егетләр! Герман сугыш башлаган!

**Яшьләр.** Сугыш? (Бар да тынып кала)

**Алып баручы.** Радио фашистлар Германиясе Советлар иленә вәхшиләрчә һөҗүм ясавы турында шомлы хәбәр китерә (Экранда **Видеоролик «Изге сугыш» «Священная война»**). Бөек Ватан сугышы башлана.

**Алып баручы.** 1418 көн барган дәһшәтле сугышның никадәр сузылачагын әле беркем белми. Алда билгесезлек… Шуңа саубуллашулар да бигерәк сагышлы. Авыл – баһадир яшьләрен, кызлар – сөйгән ярларын, аналар – улларын, яшь хатыннар сөекле ирләрен сугышка озатты ул көнне. Ир-егетләрнең җырлары бүген дә яңгырап тора сыман. (Яшьләр **«**Герман**»** көенә җырлый-җырлый сәхнә артыннан котомкаларын киеп чыгалар, сугышка китәләр. Тавышлары ерактан ишетелеп тора. Кызлар кулъяулык болгап аларны озата барарлар):

Сары каеш, ак дилбегә
Безнең атларда гына.
Иртән торсам, ике күзем
Сезнең якларда гына.

Без урамнан үткән чакта
Күтәрелде томаннар.
Я кайтырбыз, я кайтмабыз,
Сау булыгыз, туганнар.

**Алып баручы.** Бүген һәм киләчәк… тарих һәм мәңгелек…Безнең буын бу кан койгыч сугышны ишетеп кенә белә, ләкин әти-бабалырыбыз, тылдагы әни-әбиләрнең каһарманлыгын аңлау, җырлар, китаплар, кинофильмнар аша безгә сеңгән. Җыр-моңнарыбыз ирексездән әнә шул төшенчәләр турында уйларга этәрә. Сугыш тәэсирендә туган әлеге дәһшәтле елларга багышланган җырлар гади җырлар гына түгел, алар тарихыбызның аяусыз сәхифәсе шаһитлары, каһарманлык символы, сагыну. Юксыну авазы да. Роберт Әхмәтҗан сүзләренә Фәтхерахман Әхмәдиев иҗат иткән

«Солдатлар» җыры татар сәнгатендә әлегә кадәр Бөек Ватан сугышы темасына багышланган иң уңышлы җырларның берсе.

**Экранда сугышка озату күренеше. Сәхнә халык белән тула** (ир-егетләр, хатын-кызлар, кечкенә балалар, өлкән яшьтәге кешеләр, һ.б.). Кайберләре фронтка китә, икенчеләре озатучылар. Кочаклашулар, елаулар, гармун тавышлары яңгырый. (**«**Җиңү көне**»** презентациясендәге рәсемнәр)

**«Солдатлар» Роберт Әхмәтҗан сүзләре, Фәтхерахман Әхмәдиев музыкасы (егетләр ансамбле).**

**Алып баручы.** Тирә-якта кан койгыч бәрелешләр бара, туплар шартлый, киләчәккә бернинди өмет калдырмаучы коточкыч кан коеш. Шушы мәхшәрдә кыска гына вакытта урнашкан тынлык…

**Экранда сугыш вакыты чорындагы гармунчы солдатлар сюжеты бара(«Гармунчы солдатлар» папкасыннан рәсемнәр).**

**Алып баручы.** Каяндыр ерактан сызылып гармун тавышы ишетелә. Әлеге аваз яралы тәнгә, үксегән җанга дәва, сагындырып төшкә керә торган туган яктан хәбәр, үз солдатын тилмереп көткән газиз күзләрне күрергә ышаныч.

**«Гармуным» т.х.ж. (гармунда попурри)**

**Алып баручы.** Сугыш чорының иң легендар җырларның берсе – «Катюша». Ул җырны 1938 нче елда Михаил Исаковский сүзләренә композитор Михаил Блантер иҗат итә. Бу җыр халык җырына гына түгел интернациональ җырга әверелә. Фашистлар белән көрәшүче Италия партизаннары да, французлар да бу җырны үз итә. Һәтта Италиядә «Катюша» гимнга әверелә. Бу җырның популярлыгы шуннан да билгеле, хәтта Гитлер армиясе дә «Катюша» сүзен ишетүгә куркуга калып, калтырана башлый…

**Катюша биюе. Егетләр, кызлар.**

**Экранда солдат хатлары, («Солдат хатлары» папкасыннан рәсемнәр), салмак көй яңгырый.**

**Алып баручы.** Сугыш кырыннан кайткан хатлар… Өчпочмаклы ак, зәңгәрсу, саргылт конвертлы, читенә кыр почтасының тәртип саны куелган,

штемпель сугылганнары. Төрле телдәге бу хатларда бер максат, бер уй, бер теләк: Җиңүгә ышаныч! Шул ук вакытта һәрбер хат хуҗасының үз дөньясы, үз куркуы, үз өмете.

**«Сугыштан хат» Рәзил Вәлиев сүзләре, Рәшит Абдуллин музыкасы**

**(«Гүзәл затлар һәм балалар» папкасыннан рәсемнәр)**

**Алып баручы.** Солдат хатынныры! Солдат балалары! Аларның тормышлары михнәтле тамаклары ачлы-туклы, күңелләре тулу сагыну иде. Эшенә, ачлыгына түзәр идең, хатыннарны тол, бала-чагаларны ятим итеп авылга туктаусыз кара печатьле кәгазьләр агылды.

**Сценка – балалар утырып сөйләшә.**

**(Балалар түгәрәкләнеп утыралар да , үзара сөйләшәләр).**

- Бүген минем әтием сугышка китте.

- Ә минеке кичә үк китте инде.

- Минем абыем күптәнннән армиядә инде.

- Минем апам да анда шәфкать туташы.

- Минем әтием күптән сугышта, нишләптер һаман хаты килми. Нишләп язмыйдыр ул? Вакыты юкмы икән? Гәҗитләрдән укып торабыз инде. Калининград фронтында бик каты сугышлар бара икән. Әй, хат түгелдер шул аларның уенда.

(шулвакыт Азатның сеңлесе йөгереп керә.Кулында өчпочмаклы хат.)

- Абый. Син кайда? Кил әле тизрәк. ( Азат йөгерә, хатны алмакчы була)

- Абыем, бу хатны әле генә хат ташучы алып килде, мә укып кара әле....мә әле...Мин укый алмыйм.

- Нишләптер бу хат әти кулы белән язылмаган.

(Азат ача һәм укый.)

**Сәлам, фронттан!**

Азат энем, сезнең хатны алып укыдым.Сез анда әтиегезгә зур уңышлар телисез, аның сезгә еш хат язуын үтенәсез. Энем Азат, гафу итегез, әтиегез башка сезгә үз кулы белән хат яза алмый инде, ул бу аяусыз

сугышта,солдат бурычын үтәгәндә, һәлак булды. Без сезгә сүз бирәбез,аның үлеме өчен фашистлардан үч алачакбыз.

- Әти! Әтием! Син хәзер бөтенләй юкмени? Юк, ышанмыйм, ышанмыйм мин моңа. Әтием! Син исән, исән!

- Менә икән эш нәрсәдә этием! Менә ни өчен озак язмагансың икән... Хәзер синнән бервакытта да хат килмәс микәнни безгә. Ә без әнием белән синнән хатлар көткән идек, көткән идек...

**«Хатлар көтәм авылдан» Разил Вәлиев сүзләре, Луиза Батыр-Болгари көе. Җырны хатлар биюе белән дә кулланырга мөмкин.**

**Алып баручы**. Солдат хатлары канатлы кош кебек ерак-еракка оча. Дөресрәге, ерактагы якыннарга, әти-әнигә, дусларга, сөйгән ярга. Һәрбер юл, һәрбер сүз яңадан яңа мәгънәләр салып бик күп тапкырлар укылгандыр да сагыну авазы булып җырларга күчкәндер. Зарыгу, сагыну… Сугыш вакытында бу сүзләр кергән җырларның халык арасында тиз таралуын аңлату кыен да түгел.

**«Көтәм сине» Әхмәт Ерикәй сүзләре, Сара Садыйкова музыкасы**

**Алып баручы. «**Барысы да фронт өчен, барысы да җиңү өчен**»**, дип тылда фидакарь хезмәт батырлыгы күрсәткән әби-бабаларыбыз фашист илбасарларын юк итүдә хисапсыз күп өлеш керттеләр. Яшүсмерләр, хатын-кызлар үзләрен аямыйча фронтка икмәк, кием-салым, сугыш кирәк яраклары белән тәэмин иттеләр Бөек Җиңү өчен! Бөек Җиңүне якынайтуга зур өлешләрен керткән, Фронт өчен дип бер таңнан икечесенә кадәр эшләүче хатын-кызлар, балалар, картлар бүген сезнең алда баш иябез, сезгә чиксез рәхмәтебезне белдерәбез.

**«Солдатта булган, диләр» Шамил Маннанов сүзләре, Гариф Нигъмәтҗанов музыкасы**

**Экранда хатыннар, кызлар сүрәтләре (Экранда «Гүзәл затлар» папкасыннан рәсемнәр).**

**Алып баручы.** Әйе, сугыш – ул җимерелгән шәһәрләр, ату тавышлары, үле солдатлар гына түгел, күпме хатын-кызларның җан ярасы,

ялгызлыгы да. Кияүгә чыкмаган, чыгып та ир рәхәтен татырга өлгермәгән, кулында әллә ничә бала белән калган тол хатыннарның мәңгелек сагышы, җимерелгән язмышлар, ачы күз яшьләре. Алар арасында ахырга кадәр көрәшкән, соңгы минутларына кадәр өмет итеп көткәннәре дә бихисап.

**«Һаман көтәсең» Рифгать Закиров сүзләре, Сафьян Ибраһимов музыкасы.**

**Алып баручы.** Сугышта җиңүдән, сугышны җиңү мең артык дигән бер акыл иясе. Ләкин нишләтәсең, тарихта ялгашлар өчен бүгенге көндә җавап биреп булмый. Үткәнне ничек бар шулай кабул итү көчлеләр сыйфаты. Бәлки үткән вакыйгалар безгә гыйбрәт булып җибәрелгәндер дә. Әрнү, сагыш, яралар күңелдә моң булып һаман да яши бит!

**(Шушы вакытта хорга чыгып басалар.)**

**«Җиңү килде» Рамазан Байтимиров сүзләре, Рөстәм Яхин музыкасы**

**Алып баручы.** Бөек Җиңүгә 75 ел! Илебез азатлыгы өчен көрәшкән солдатларны онытмыйк.

Исәннәрнең кадерен белик
Үлгәннәрнең каберен белик!
Җиңүләрнең даны мәңгелек!

**Нәфис сүз. «Җиңүләрнең даны мәңгелек» Л.Садриева чыгышы.**

**Җиңүләрнең даны мәңгелек.**

Җиңү көнен бәйрәм итә халкым,
Яз китергән җиңү назларын.
Тик күпләрнең гомерләре кайткан
Җаны булып киек казларның.
Ветераннар, данлы ветераннар,
Сирәгәя бара сафлары.
Өзгәләнеп искә алдылар
Көрәшләрдә узган чакларны.
Яу кырында күпме җаннар калган

Туганнардан калган каберлек.

Айлар, еллар үтә җанны телеп,

Җиңүләрнең даны мәңгелек.

75 нче тапкыр язлар килә,

Җиңү гөлләренә төренеп.

Илебездә тик тынычлык булса,

Яшәр халкым, яшәр сөенеп.

(Лилия Садриева.)

**Мөслим район башлыгы Муллин Р.Х. ның чыгышы.**

**Хор. «Матур булсын» т.х.җ.**

Ветераннар һәм сугыш чоры балаларының чыгышлары концерт номерлары белән аралашып дәвам итә.

## Файдаланылган әдәбият.


1. Ватан өчен. Җыентык.

2. З. Мәҗитов. «Сугышчан поэзия», Казан, 1975 ел.

3. Фотолар интернет – ресурслардан алынды (Бөек Ватан сугышы турында рәсемнәр).

4. Казан утлары №1 2005 ел.

5. Нәсыйфулла Хәйруллинның шәхси көндәлеге.

6. Ә.Шәрипов «Утлы еллар аша», Яр Чаллы, 2014 ел.

**Татарстан Республикасы**

**Мөслим муниципаль районы**

**Мөслим балалар сәнгать мәктәбе**

# ӘДӘБИ МУЗЫКАЛЬ КИЧӘ

# «КАЛФАКЛЫ САНДУГАЧ»

(Сара Садыйкованың тууына 115 ел)

**Сценарий авторы:**

**югары категорияле**

**вокал бүлеге укытучысы**

**Юсупова Гөлназ Моряк кызы**

**Мөслим 2021 ел**

**Аңлатма язмасы.**

Татар халкының танылган җырчысы, композиторы Сара апа Садыйкованың тууына 115 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль чара («БУЫННАР ОЧРАШУЫ» циклы)

Чарада катнашучылар Сара Садыйкованың биографиясе һәм иҗаты белән җентекләп таныша алачак, электрон презентация белән тәэмин ителәчәк. Чара барышында композитор-башкаручы җырлары, шигырьләр яңгыраячак. С.Садыйковага багышланган китап күргәзмәсе эшләячәк. Шулай ук әлеге күргәзмә буенча күзәтү узачак. Татарстан Республикасының бөек композиторының иҗатын яратучылар шигърият һәм музыка дөньясына чумып, күңел балансын ала алачаклар.

**Максат:**

♦♦♦ Бөек композитор Сара Садыйкованың тормыш юлы, ижаты белән таныштыру;

**Бурычлар:**

♦♦♦Композиторның музыкаль драма, комедияләр өчен иҗат иткән әсәрләрен киң катлау тамашачыларга җиткерү,

♦♦♦ тамашачыларда халык композиторы иҗатына ихтирам, мәхәббәт тәрбияләү.

**Җиһазлау.** Интерактив такта, синтезатор, музыкаль аппаратура, презентация, видеоязмалар, аудиоязмалар, китаплар.

Зал бәйрәмчә бизәлгән. Уртада Сара Садыйкова портреты.

Композиторның тормышын, аның иҗади эшчәнлеген тасвирлаучы фотовыставка. Стендка Сара Садыйкова турындагы китаплар, ул язган җыр ноталары кургәзмәсе куелган.

**«ТУГАН АВЫЛЫМА»**

**(Харитонова Рената)**

**Сара Садыйкова** музыкасы **Мостафа Ногман** сүзләре

**1 нче алып баручы(ЭЛИЗА):** Хәерле көн! Исәнмесез, хәерле көн татар музыкасына гашыйклар: укытучылар һәм укучылар, әбиләр һәм бабайлар, хөрмәтле тамашачылар! Ишетәсезме, ишетәсезме, сихри көй агыла, кунелләрнең нечкә кылларын тирбәндереп татар моңы, татар җыры, татар рухы.

**2 нче алып баручы(РУШАН):** Татар милли опера театрына нигез салучыларның берсе, аның озак еллар дәвамында моңлы тавышлы солисткасы, композитор буларак 400 дән артык, җыр, романс авторы, татар музыкасында беренчеләрдән булып танго стилен кертуче, вальс иҗат итүче Сара ханым Гариф кызының бүген юбилей кичәсенә җыелдык.

**3 нче алып баручы(БУЛАТ):** Халкыбызның моң чишмәсе, Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның халык артисткасы, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт буләге лауреаты, мәшһүр композитор, җырчы Сара Садыйкованың тууына 1 ноябрь көнне 110 ел тулды.

**ВИДЕОЯЗМА**

**4 нче алып баручы(ГҮЗӘЛ):** Сара апаның бала чагы ничек булган, ничек үткән соң?

Аларның гаиләсе хәзерге Киров һәм Чернышевский урамнары чатындагы иске йортта өч тәрәзәле ярымподвал өлешендә яшәгән. Тик бу йорт Сара апа туган йорт түгел. Ул Париж Коммунасы урамындагы иске ике катлы йортта дөньяга килгән. Булачак әтисе белән әнисе – Гариф белән Бибигайшә - шушы йортка кунакка килә.Туган тиешле апаларында җырлап-биеп күңел ачып утырганда, Сара дөньяга туа. Әтисенең ап-ак ситсы күлмәген салдырып алып, аны ертып, чүпрәк ясап, кечкенә бәбине төреп,

әнисе кулына тоттыралар. 1906 нчы елда дөньяга килгән Сараның җыр, моң дигән гүзәллек нуры сибүче йолдыз булачагын ул вакытта беркем дә белми әле.

**ЭЛИЗА:** Шундый шартларда туган бала сайрар кош, сандугач булмыйча кем булсын? Гармунлы, җырлы, биюле балачагын искә төшергәндә, Сара апа әтисе белән әнисе турында бик зур мәхәббәт белән сөйли, "Әткәй таза, матур, сабыр холыклы кеше иде. Бик яшьтән үк эшли башлаган ул. Әнкәй шундый сөйкемле, акыллы, шактый укымышлы иде. Безнең әнкәй тегү-чигүгә бик оста иде. Ә өстәвенә бик матур итеп саратский гармунда уйный иде. Без, балалар, әнкәйдән күрмәкче, барыбыз да җырлап үстек. Беренче музыка кичерешләрен ул болай дип яза: «... 5-6 яшемдә гармунда уйнарга өйрәндем. Үзем уйныйм, үзем җырлыйм. Минем беренче сәхнәм - өстәл асты булды.Өйдә кунаклар җыелганда минем гармун уйнап җырлавымны сорыйлар,ә мин ояла идем, шуңа күрә өстәл астында качып, я чаршау артына кереп «концерт» бирә идем...»

**РУШАН:** Балачагының искиткеч матурлыкта, сәнгать белән бәйләнештә узганын ул сагынып искә ала:

«Шунысы исемдә: без кечкенәдән матур әдәбият белән танышып үстек. Әткәй безгә китап-журналларны ташып кына торды. Нинди генә китап юк иде! Тукай дисеңме, Фатыйх Әмирхан, Лермонтов, Пушкин... Ә уен кораллары! Кубыз, курай, 2 гармун бар иде. Хәтта зур торбалы грамофон да бар иде. Исемдә, әткәй белән әнкәй безне кинога, театрга бик еш йөртәләр иде. Әнкәй миңа бик матур күлмәк, калфак кидертә иде. Театрның бинасына керү белән минем өчен бәйрәм башлана иде. »

**БУЛАТ:** «Әткәй, әнкәй» дип өзелеп әйтүеннән үк аның әти-әнисенә хөрмәте сизелеп тора. Чынлап та, яратырлык итеп, матур итеп тәрбия биргәннәр алар Сара апага. Балаларын белемле итәргә тырышканнар, аларның җырга-биюгә булган сәләтләрен сүндермәгәннәр,

киресенчә, музыканы, бию сәнгатен аңларга өйрәткәннәр. Сараны укырга ул чорның алдынгы карашлы булган Фатиха Аитованың «татар кызлар гимназиясе»нә бирәләр.

Фатиха Аитова – бик таләпчән укытучы.Ул Сараны хәтта мәктәптән дә куып чыгара. Моның сәбәбе – җыр. Дус кызы Әминә аны Фәхрелислам Агеев хорына алып килә. Сара җырлый. Фатиха Аитова кызның җырлавын ишетә дә мәктәптән куа, чөнки ул елларда ир балалар белән кыз балаларның бергәләп тезелешеп басып җырлавы инсафсызлык саналган. Бераздан, укытучы Сараны яңадан мәктәпкә чакыра, чөнки революциядән соң мәктәптә хәлләр үзгәрә, җыр дәресләре, хор белән җырлаулар Сараның иң яраткан шөгыленә әйләнә.

**<u>«БӨТЕН ГОМЕРГӘ»</u>**

**(Мөршидә Әхмәтҗанова)**

**Сара Садыйкова** музыкасы **Галимҗан Латыйпов** сүзләре

**<u>ГҮЗӘЛ:</u>** Менә шул елларда ук инде Сараның халкыбызның борынгы көйләргә, халык җырларына мәхәббәте үсә. Еш кына Сара сеңлесе Разия, энесе Хафиз, Салих белән шаярып, үзенең «артистлыгын курсәтә». Педагогия техникумында уку чорында яшь Сара татар халкының беренче композиторы Солтан Габәши белән очраша, ул оештырган хорга йөри, уку йорты әзерләгән спектакльләрдә жырлы рольләрне башкара. Кызның саф, матур тавышына, спектакльләрдә рольгә кереп уйнавына сокланып, Солтан Габәши: «Бу бала җырчы артистка булырга тиеш!»- дигән фикергә килә.

**ВИДЕОЯЗМА**

**<u>ЭЛИЗА:</u>** 1922 нче ел. Мәскәү. Сараның музыкаль талантын сизеп аны Мәскәү консерваториясенә укырга җибәрәләр. Сара имтиханнарны үтә һәм консерваториянең махсус бүлегенә кабул ителә, вокал буенча белем ала. Менә ул Чайковский исемендәге консерватория укучысы! Сарага бөтен

Мәскәү, бөтен дөнья тоташ бер көй, мең тавышлы жыр җырлый кебек тоела. Илебез кичергән авыр елларның чагылышы яшь Сараның куңелендә туган моңлы образлар булып сәхнәгә менә.

**РУШАН:** Сара беренче мәхәббәтен Мәскәүдә укыган чагында очрата. Казан тамашачысын үзенә каратып өлгергән артист Газиз Айдарский була ул. Казанда Газиз Айдарскийны Сара берничә тапкыр күргән була, Мәскәү аларны янә очраштыра. Алар арасында мәхәббәт күпере салына. Газизнең фамилиясе – Вәлитов. Айдарский – сәхнә псевдонимы. Ул Мәскәүдә Луначарский исемендәге театр институтында укый. Сара кичәләрдә, концертларда катнаша, җырлый, үзен таныта башлый. Җырлавын бик яраталар. Ә Газиз аның тавышыннан сихерләнә. Мәхәббәт турында сүз белән сөйләшмәгән бу ике яшь йөрәк җыр, моң аша аңлаша.

**«ӘЙТЕРГӘ МИКӘН, ӘЙТМӘСКӘ МИКӘН?»**

**(Гүзәл Галиева)**

**Сара Садыйкова** музыкасы **Әнвәр Зарипов** сүзләре

**Экранда Сара белән Газиз хатларыннан өзекләр:**

**БУЛАТ:** Ике талантлы яшь кеше 1924 нче елда кавыша. Газиз Сарадан җиде яшькә өлкәнрәк була, баштарак аны «абый» дип йөри. Газиз дә Сарага балага караган кебегрәк карый:консерваториягә озатып куя, каршы ала. Белемгә омтылучы, эш сөючән бу егетне Сараның әти-әнисе дә,туганнары да хөрмәт итәләр. Аларның уртак бәхетләре-кызлары кап- кара зур күзле, бөдрә чәчле кызлары туа. Аңа Әлфия дип исем кушалар.

**«УФА НИ ӨЧЕН МАТУР? »**

**(Салихов Рушан)**

**Сара Садыйкова** музыкасы **Нәби Дәүли** сүзләре

**ГҮЗӘЛ:** 1927-1928 нче еллар. Мәскәү, Ленинградта укучы татар җырчылары: Сара Садыйкова, Асия Измайлова, Разыя Садыйкова (Сара Садыйкова белән бертуган) һәм башка артистлар Казанга кайтып концертлар

бирәләр. Сара ханымның тавышы матур булганга аны «**Татарстан сандугачы»** дип йөртәләр.

**«<u>ЧИТ ИЛЛӘРГӘ ЧЫКСАҢ</u>»**

**(Латипов Азат)**

**Сара Садыйкова** музыкасы **Илдар Юзеев** сүзләре

**<u>ЭЛИЗА:</u>** 30 нчы елларда Мәскәүдәге «Эшче» театрында, шулай ук Казандагы татар драма театрында эшләп, Сара Садыйкова – татар опера театрына нигез салучыларның берсе. Опера театры сәхнәсендә күп кенә

онытылмаслык образлар иҗат итә. Ул «Эшче» операсында - Сәлимә, «Сания» операсында - Сания, «Башмагым» музыкаль комедиясендә - Сәрвәр, «Наемщик» музыкаль драмасында – Зөбәрҗәт. Татар опера сәхнәсендә матур образлар тудырганы, сәнгатьне үстерүгә күп көч куйганы өчен Сара Садыйкова шул елларда ук «Татарстанның атказанган артисткасы» дигән мактаулы исемгә лаек була.

**ВИДЕОЯЗМА**

**Сара Садыйкова башкаруындагы өзекне карау**

**Сара Садыйкова башкаруында видео тасмадан җыр тыңлау**

**<u>РУШАН:</u>** Көтмәгәндә-уйламаганда, Газизнең туберкулез белән авыруы беленә. 1933 нче елның ноябрендә үлеп тә китә. Сара өчен бик авыр, сагышлы-хәсрәтле көннәр башлана.

... Беркөнне кемдер ишек шакый. Салих Сәйдәшев икән. Шактый вакыт дәшми тора да: «Сара, Газизне оныта алмавыңны беләм, бәгырь. Хәлеңне аңлыйм. Оныт дип тә әйтмим, оныту мөмкин түгел. Юатырга да җыенмыйм. Юатырга да мөмкин түгел. Җырла, җырла, бәлки, җыр хәсрәтеңне җиңеләйтер. Җырның без белеп бетермәгән серле көчләре бар,» -диде.

## **«МИН СИНЕ НИЧЕК ЯРАТТЫМ»**

**(Гөлназ Хафизова)**

**Сара Садыйкова** музыкасы **Лена Шакирҗанова** сүзләре

**БУЛАТ:** Кызы Әлфия дә сәнгать юлын сайлый. Ул Ленинград бию училищесына укырга керә. Сара апа борчыла: тугыз яшьлек бала әнисез ничек яшәр?! Шул ук вакытта шатлана да, чөнки өч йөз бала арасыннан уникe генә баланы сайлап алганнар. Ана өчен шатлык бу! Әлфия балерина булып китә. 1938ел, укулар тәмам. Студия белән саубуллашып бер төркем артистлар һәм композиторлар Казанга кайталар.

## **«КАЗАН КИЧЛӘРЕ»**

**(Ханнанова Лилия)**

**Сара Садыйкова** музыкасы **Хәсән Туфан** сүзләре

**ГҮЗӘЛ:** 1939 елның 17 июне. Качалов исемендәге Казан Дәүләт Зур Драма театры бинасы. «Качкын» спектакле белән Татар Опера театры ачыла. Беренче тапкыр пәрдә ачылып, зур сәнгать юлы башлана. Бер-бер артлы татар опералары, музыкаль комедияләре иҗат ителеп, сәхнәгә куела. «Галиябану» (Мансур Мозаффаров), «Ирек», «Илдар» (Нәҗип Җиһанов), «Башмагым» (Җәүдәт Фәйзи) спектакльләрендә Сара Садыйкова җаваплы рольләрдә уйный, кызыклы образлар иҗат итә...

**ВИДЕОПРЕЗЕНТАЦИЯ**

**ЭЛИЗА:** Шушы чорда Сара апа өчен авыр көннәр башлана, аны күп сәбәпләр табып театрдан кыскарталар. Ул моны бик авыр кичерә.Театрдан китсә дә артистка музыкадан аерылмый. Сара ханым шатлыгын да, хәсрәтен дә пианино артына утырып, иң якын дусты, сердәше, юанычы һәм куанычы булган музыка белән уртаклаша. Еллар узгач аның күңелендәге моң һәм

тиңсез таланты чишмә булып икенче үзәннән ага башлый. Сара ханымның икенче гомере – композиторлык чоры башланып китә.

**«АКБУЗАТЫМ»**

**(Габдрахманов Илвир)**

**Сара Садыйкова** музыкасы **Галимҗан Латыйпов** сүзләре

**РУШАН:** Сара Садыйкованың җырлар яза башлавына күренекле композиторыбыз Салих ага Сәйдәшев сәбәпче була. Шунысы игътибарга лаек, Сара Садыйкова иң беренче көен нәкъ менә Салих Сәйдәшев кушуы буенча яза. Театрның 1931-32 нче елгы сезоны. Кәрим Тинчуринның «Кандыр буе» музыкаль драмасына Фәридә ариясен иҗат итә. Аннан соң Кәшифә Тумашева яңадан сәхнәләштергән Мирхәйдәр Фәйзинең «Ак калфак» спектакльленә көйләр иҗат итә. Шулай итеп, Сара Садыйкова композиторлык эшенә тирәнрәк керә бара. Академия театры, Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры, Башкорт академия театры, Татар дәүләт күчмә театры, Сара Садыйковага заказ биреп, бик күп спектакльләргә музыка яздыра. Сара Садыйкова төп эшеннән башка, Казанның «Спартак» аяк киемнәре берләшмәсе каршындагы М. Горький исемендәге клубта да эшли. Эшче яшьләр, халык белән якыннан аралашу композиторлык иҗатына уңай йогынты ясый. Берсеннән-берсе матур җырлар языла. Үзенең сәхнәдә жырламавына ул инде борчылмый. Әйтерсең шулай кирәк булган, аның җырчылыгы, чишмәнең чыганагы шикелле, композиторлык иҗатының башлангычы булып яшьлегендә кала.

**(Сара апа музыкасы яңгырый.)**

**БУЛАТ:** Сара Садыйкова үзенең әби- бабалары, әнисе яшәгән Апас районы Тутай , Кызыл Тау авылларына , туган ягым дип, бик еш кайтып йөри. Чөнки аның моң чишмәләре, зур дәрья кебек киң иҗатка юл башы

шушы авыллардан башлана. Аның күп кенә җырлары шушында туа. «Иртәнге нур», «Дөнья матур, дөнья киң» дигән матур көйләре Тутай кырларында тургай сайравын тыңлап иҗат ителгән.

**«<u>ИРТӘНГЕ НУР</u>»**

**(Идиятуллина Сабина)**

**Сара Садыйкова** музыкасы **Зиннәт Вәли** сүзләре

**<u>ГҮЗӘЛ:</u>** Кичәбездә Гомәр Бәширов сүзләренә язылган «Җидегән чишмә» җыры турында әйтмичә китү мөмкин түгел. Заманыбызның данлыклы, күренекле әдипләре белән мине шигърият дуслаштырды, —дип искә ала Сара апа. Гомәр Бәширов миңа «Җидегән чишмә»сүзләрен тәкъдим иткәч, мин бик куандым һәм уйланып калдым. Шундый шигъри, музыкаль сүзләргә нинди көй кирәк булыр икән дим. Мин ул көйне озак эзләдем. Үземне күңелемнән шул чишмә янына илтеп куйдым. Күңелем белән генә түгел, мин, чынлап та, кайбер көйләремне су буйларында, таллар арасында кешеләрдән качып, табигать белән күзгә-күз калып чыгарам... «Җидегән чишмә» көе беренче башлап иртәнге сәгатьләрдә Идел буйларында йөргән чагымда күңелемә килде. Идел кебек киң булып, Идел кебек ярсулы булып уянды ул көй минем йөрәгемдә. Бу көй Гомәр Бәшировка да бик ошады «Җидегән чишмә» җыры безнең уртак шатлыгыбызга әйләнде. Халык бу җырны тиз күреп алды һәм яратып өлгерде.

**<u>«ҖИДЕГӘН ЧИШМӘ»</u>**

**(Латипов Булат)**

**Сара Садыйкова** музыкасы **Гомәр Бәширов** сүзләре

**<u>ЭЛИЗА:</u>** Татарстанның халык артисткасы,РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булган Сара Садыйкованың җырлары мәңгегә безгә калды. «Әй язмыш,

язмыш» җыры — Сибгат Хәким белән Сара Садыйкованың бергә иҗат иткән иң яхшы җырларыннан берсе. Бу җыр, бик күп җырчыларның репертуарыннан төшмичә, бик күп еллар яңгырап халык күңелендә яши. Әлеге җыр турында Сара апа болай дип искә ала: “Кояшлы көзге иртә. Кухняда сөтле чәй эчеп утырам. Кара икмәккә май ягып. Кәефем яхшы, күңелем шат! Нәрсәгә шатландыммы? Үземнең илемдә,үз почмагымда тыныч кына гомер кичерүемә. Күңелем шулхәтле шатлык белән тулды, икенче бүлмәгә күчтем дә көй чыгардым. Көйне бит җырлап та карарга кирәк әле, үзем өчен генә болай дип җырладым: «Әй язмыш, бәгърем, аерма мине туган илкәйләремнән, сөтле чәемнән, кара икмәгемнән, ак каеннарымнан. Икенче көнне бу сүзләрне Сибгат Хәкимгә җибәрдем. Шушы үлчәмдә сүз язып бир әле дип. Берничә көннән әзер текст килде. Сара апа, минем көйне ишеткәнем юк, вәзеннәре ярар микән, дигән Сибгат. Сибгатнең үзенең бер шигырендә язганча «Гыйльметдин ясаган тәрәзә рамы» кебек, керде дә утырды шигырь! ..»

**<u>«ӘЙ, ЯЗМЫШ, ЯЗМЫШ»</u>**

**(«Мөслим нуры» вокаль ансамбле)**

**Сара Садыйкова** музыкасы **Сибгат Хәким** сүзләре

**<u>РУШАН:</u>** 1941 нче елның 22 нче июне. Сугыш. Җыр, музыка тынып кала.

Бу көнне Сара-сандугач та тына, тик вакытлыча гына. Туктап калырга ярамый, халыкның рухын күтәрергә кирәк. Шундый уй-теләкләр белән яна. Күңеле белән сизгер Сара кайбер җитәкчеләрнең үзенә кырын каравын тоя. Борчыла. Кызып китеп, театрдан җибәрүләрен сорап, гариза яза. 1941 елның көзендә театрдан китә. Эшсез кала. Нишләргә? Кая барырга? Сараның күңелен аңлаучы бердәнбер кеше була. Ул- музыкант, милләте белән литвалы Юлий Станиславович Крещелюнас, тол ир Сараны хөрмәт итә. Вакытлар

үтү белән, дуслык мәхәббәткә әйләнә һәм алар өйләнешәләр. Һәр гаиләгә кайгы-сагыш китергән сугыш Сараларның ишеген дә шакый, Юлий сугышка китә, һәм хәбәрсез югала.

**БУЛАТ:** Сара апа хат-хәбәр көтеп йөргәндә, кулына бер газета килеп керә. Анда шагыйрь Әхмәт Ерикәйнең «Көтәм сине» шигыре басылган. Сара апа да, башка бик күп хатын-кызлар да якыннарының сугыштан кайтуларын зур өмет белән көтәләр. 1942 нче елның кышкы салкын җилле көне. Трамвай тукталышы. Халык. Ә трамвай юк. Сараның ботинка гына кигән аяклары туңа. Ул бер аягын икенчесенә бәрә-бәрә, әлеге шигырьне авыз эченнән генә көйгә сала, кабатлый.Трамвай килә. Барлык кеше утырып китеп бара. Сара моң ташкыныннан аерыла алмый,күңеленнән дәрья булып көй агыла. Җыр туа. Бу көй – татар музыкасы дөньясында беренче танго. Әлеге җыр халык арасында бик тиз тарала: аны җырлыйлар, матур ритмына танго бииләр. «Көтәм сине» җыры меңләгән толларның йөрәк сагышы булып, күңелдән күңелгә керде.

**ВИДЕОЯЗМА**

**( Җыр «Көтәм сине», Әхмәт Ерикәй сүзләре , Сара Садыйкова көе)**

**ГҮЗӘЛ:** Җыр сугыш кырына да барып җитә. «Социалистик Татарстан» газетасының 1981 нче елның 3 нче март санында журналист Рифкать Исмәгыйлев болай дип яза: «Хәрби госпитальгә яраланган яшь кенә бер солдатны китерделәр.Ул безнең Татарстан егете булып чыкты. Фронтта якташыңны очрату зур бәхет ул. Беркөнне лейтенант без беркайчан ишетмәгән яңа җыр җырлады:

Син кайларда йөрисең икән,
Алтыным, көләч йөзле иркәм?

- дип башлана ул җыр. Барыбыз да сихерләнгән кебек калдык. Ниндидер илаһи моң, йөрәк өзгеч сагыну һәм яшәүгә, сөйгән кешеңнең

кайтуына өмет яңгырый иде бу җырда. Җыр йөрәкләргә үтеп керә, күңелнең иң нечкә кылларын чиртә.

Күп тә үтмәде, без, сәламәтләнеп, фронтның алгы сызыгына киттек. Ул җыр гел безнең күңелләрдә кабатланып йөрде. Сугыш бетте. Бөек җиңү көне килде. Ул канатлы җыр һаман күңелләрдә яңгырый».

**ЭЛИЗА:** 1939 нчы елда Сара Садыйковага Татарстанның атказанган артисткасы, 1977 нче елда Татарстан халык артисткасы, 1984 нче елда Россиянең сәнгать эшлеклесе, 1990 нчы елда Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләренә лаек була. 1986 нчы елның 7 нче июнендә, композитор, җырчы, актриса Сара Садыйкова каты авырудан соң вафат була. «Гомеренең соңгы көннәрендә дә әнкәй бик күп эшләде. Күп җырлар язды, артистлар белән гастрольгә йөрде» - Больницада соңгы көннәре: «Әлфия, китер әле нота кәгазе, эчем тулы музыка, көй, моң бит, төшерим беразын булса да кәгазьгә!» Ләкин кулыннан каләме төшеп китте» - дип искә ала кызы Әлфия. Кызы Әлфия бүген дә исән, әнисе турында истәлекләрне бик теләп сөйли һәм әнисенең моңа кадәр халыкка танылмаган җырларын туплап, китап чыгарды.

**ВИДЕОЯЗМА**

**РУШАН:** Сара апаның киеме дә, куңеле дә матур иде.Гөлшат Зәйнашева истәлекләреннән ике өзек: «Сара апа, әллә берәр кая җыендыгызмы, матур киенеп, бизәнеп утырасыз? — дип сорагач: «Юк, беркая барырга җыенмыйм, болай гына киендем, бизәндем, өй ямьле булып китсен өчен,» - ди торган иде. Энҗе тезелгән калфагын бышына кыңгыр салмыйча, театрга, концертка бармый, халык алдына сәхнәгә чыкмый иде. Сәхнәгә ул калфагын киеп, йөзек кашы кебек булып балкып чыга иде.

**БУЛАТ:** «Сара апа якты чырайлы, киң күңелле, кешеләр белән аралашып, дуслашып яшәргә яратучан, дуслыкка тугры, кирәк чагында туп-туры әйтүчән, хәйләкәрлек, ялагайлыкны белми торган эчкерсез, бала табигатьле

кеше иде. Аның белән вакытның үткәнен сизми дә каласың.»

**<u>ГҮЗӘЛ:</u>** Ул беркайчан да үзенә карчык, әби дип әйткәнне яратмаган, бары тик апа. Ә үзе бик назлы итеп «бәбекәем», «балакаем», «күгәрченем» дип эндәшергә яраткан. Сара апа соңгы сулышына кадәр музыка иҗат итүдән аерылмаган. 80 яшь тулган көннәрдә Сара Садыйкова Казанда Татар зиратында җирләнә. Сара апа истәлегенә «Моңсара» фильмы төшерелде, Тутай авылында һәм Казанда берничә музее эшли, Яр Чаллы шәһәренең концертлар залы аның исемен йөртә. Сара апаның мирасы - аның җырлары. Кадерле композиторыбыз Сара Садыкова исеме халкыбыз күңелендә аеруча тирән мәхәббәт белән саклана.

**<u>«БЕЛЕГЕЗ ШУНЫ»</u>**

**(Хантимерова Зөләйха)**

**Сара Садыйкова** музыкасы **Илгизәр Фазлуллин** сүзләре

**<u>ЭЛИЗА:</u>** Сара апаның үлеме татар халкы өчен зур югалту булды. Мондый кабатланмас талант, мондый язмыш 100 елга бер генә була. Татар композиторларының атасы Салих Сәйдәшев булса, анасы –Сара Гариф кызы Садыйкова. Татар хатын - кызларыннан ул – беренче композитор.

**<u>РУШАН:</u>** Тормыш дәвам итә... Әнә тыңлагыз, Идел нинди тирән уелып, тирән моңнар көйләп ага! Чишмәләр ничек матур челтерәп, кояш нурында җем – җем килеп, көмеш кебек җыр сузалар! Ә кошлар, ә кошлар, кояшка, айга, йолдызларга җитсен моңыбыз дигәндәй, ничек матур итеп сайрыйлар! Ә кешеләр, кешеләр җырлый ...

**<u>«КАЙТЫГЫЗ, ТОРНАЛАР»</u>**

**(Замалова Гүзәл)**

**Сара Садыйкова** музыкасы **Илсөяр Ганиева** сүзләре

**<u>БУЛАТ:</u>** Сара Садыйкованьң музыкаль ижаты халыкчанлык белән сугарылган. Аның ижат чишмәләренең чыганаклары - халык көе, халык моңы. Халык көен, халык моңын Сара Садыйкова заманча аһәңнәр белән баетып, заманча ритмнар белән үрелдереп, яңа моңнар тапты. Гомүмән, аның

ижатына бай тематика, жырларына төрле характерлылык хас. Киң сулышлы гәүһәр жырлар, маршлар, салмак агышлы лирик жырлар, мәхәббәт-дуслык жырлары, куңелле вальслар, бию көйләре һәм башка шундый әсәрләр язды.

**ГҮЗӘЛ:** Кая гына бармасын Сара апа язасы җырларына илһам, дәрт, моң алып кайта. Туган жиребезнең кайсы төбәгенә генә барса да, җырда мактарлык гүзәллек таба. Сара Садыйкованың республикабыздагы күп кенә авылларга багышланган жырлары: «Актаныш таңнары», «Мөслим тугайлары», «Арча кичләре», «Минзәләм ягы», «Балтачым» - авыл кешеләре белән якыннан аралашу нәтиҗәсе. Бу жырларда туган жиргә мәхәббәт, анда яшәүче кешеләргә соклану шулкадәр көчле, композиторның мәхәббәте тыңлаучыга кучә. «Мөслим тугайлары» җырының тарихы белән якыннан таныштырыр өчен сүзебезне иҗтимагый совет рәисе Моряк Йосыповка бирәбез.

***ЙОСЫПОВ.М.Ш.*** *Сара апа истәлекләрен күз алдыннан үткәргәч, тиз генә җыр-моң әсирлегеннән чыгып та булмый. Бүгенгедәй күз алдында, сара апа "Мөслим тугайлары" җырын бүләк итү өчен үзе килде, 1972 нче ел хәзерге "Мизгел" элекке культура йорты халык белән шыгрым тулы, район җитәкчеләре, яшьләр, өлкәннәр, җыр-моң сөюче Мөслимлеләр залда, ниһаять сәхнәдә Сара апа, һәрвакыттагыча гаҗәеп мөлаем, бераз гына серле, зәвык белән киенгән, энҗе калфагын балкытып "Мөслим тугайлары" җыры тарихын сөйли башлады: "Җитәкчеләрегез мөрәҗәгать итү белән, бик теләп эшкә алындым, чөнки Мөслим үзенеңтабигате, Ыгы, тугайлары белән һәркемне җәлеп итә, монда чын мәгънәсендә, җырга-моңга битараф булмаган халык яши, көй бик тиз язылды. Берничә шагыйрьгә мөрәҗәгать итсәм дә миңа ошарлык шигырь тиз көндә була алмады. Шуннан тоттым да сүзләрен дә үзем яздым. Менә шулай барлыкка килде "Мөслим тугайлары" җыры.*

*Сара апа фортепиано артына утырды һәм яңа моң агыла башлады, ул берничә мәртәбә башкарды Җырны сүзләре белән башкаручы, озак еллар культура бүлеген җитәкләгән, соңырак башка җитәкче постларда эшләгән Гаяз абый  Авзалов  башкарды. Берничә мәртәбә кабатлагач, сүзләрен кулга алып, залдагы халыкта җырга кушылды. Менә шулай кабул ителде яңа җыр. Һәм ул Хәйдәр Бигичев кебек атаклы җырчылыр тарафыннан да үз ителгән, популяр җырга әверелде.*

*Гаяз абый мәрхүм бу җырны бик яратты, еш башкарды, Мөслимнең ул визит карточкасына әверелде, кече улы Ленарны I класска укырга алып килгәч тә, ул бу җырны Белем бәйрәмендә башкарды һәм ни кызганыч, шуннан соң 10 көннән, йөрәк авыруы белән безнең арадан китеп тә барды. Ул да Сара кебек җырга, туган ягына гашыйк, җәмәгать эшлеклесе иде. Озак еллар Мөслим мәктәбенең ата-аналар комитет рәисе булып эшләде.*

*Сара апаның иҗаты белән аралашып якыннан таныш кешеләр шактый Мөслимдә. Спартак аяк киеме берләшмәсе каршында эшләгән М. Горький клубында Сара апа татар хоры оештыра. Бу хорда озак еллар Табын кызы Сабирова Гөлфия җырлый, соңырак безнең якташыбыз, галим, мәгариф министры Васил Гайфуллин  да бу хорга кушыла. Ул үзенең истәлекләрендә Сара апа турында бик ихтирам белән, яратып  - чын мәгънәсендә халык композиторы, калфаклы сандугач дип искә ала.*

*Чынлап та, Сара Садыйкованың үзенә генә хас үзенчәлеге инде ул калфак. Энҗе  калфагын киеп, йөзек кашы кебек булып балкып сәхнәгәчыга иде. Шул калфаклары белән дә кадерле ул безгә Сара Садыйкова. Ул калфаклар да Сара апаның үзе кебек әллә нинди моң, әллә нинди  матур көйләр беләләр шикелле. Чынлап та ул калфакларның үзенә күрә сере дә бар икән. «Калфак кигән хатын-кыз матур, күркәм күренә, калфак кигәч үзеңне әдәпле тотасың, чөнки башына калфак кигән хатын- кыз әдәпсез була*

*алмый» дия торган иде композитор ханым. Сара Садыйкова чын мәгънәсендә татар сандугачы. Соңгы көннәренә кадәр, ә ул 1986 елда, каты авырудан соң вафат була,ул иҗат эчендә булды.*

*Менә шулардан чыгып, чираттагы "Буыннар очрашуы" циклын без татар калфагына багышларга булдык. Башта I генә очрашу планнаштырган идек, соңырак, Сара апа иҗатын һәм татар калфагы икесе дә киң масштаблы тема икәнен искә алып, очрашуны 2 өлешкә бүлдек, бүген "МОҢСАРА", "Калфаклы сандугач" Сара ханым иҗаты белән танышу булса, икенчесе – татар калфагы тарихы буенча булачак. Ансы тарих музеенда узачак. Ә хәзер сезнең фикерләрне көтәбез. Рәхмәт!*

**«МӨСЛИМ ТУГАЙЛАРЫ»**

**(«Ык буйлары» вокаль ансамбле)**

**Сара Садыйкова** музыкасы **Сара Садыйкова** сүзләре

**Файдаланган әдәбият:**

1. Сара Садыкова: Истәлекләр, шигырьләр.- Казан:Татар.кит.нәшр.,2003 ел
2. Сез яраткан җырлар., Раннур нәшр.1994ел.
3. Гөлшат Зәйнәшева «Сара Садыйкова» К., Тат.китап нәшер.,1996
4. «Калфаклы сандугач» К .,Тат. кит. нәшер., 2000
5. «Моң анасы». Эльмира Шәрифуллина мәкаләсе.
6. Видеотасма «Моңсара»

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Мөслим балалар сәнгать мәктәбе

**МУЗЫКАЛЬ КИЧӘ**

**«ВОКАЛ БҮЛЕГЕНЕҢ ЧЫГЫРЫЛЫШ КЛАССЫ**

**УКУЧЫЛАРЫНЫҢ**

**ӘТИ-ӘНИЛӘР КАРШЫНДА ИҖАДИ КОНЦЕРТЫ»**

Сценарий авторы:

югары категорияле

вокал бүлеге укытучысы

Юсупова Гөлназ Моряк кызы

Мөслим 2019 ел

**Аңлатма язмасы.**

Ата-аналар өчен отчет концерты - сәнгать мәктәбенең традицион чарасы, укучыларга үз казанышларын күрсәтергә мөмкинлек бирә, һәм ата-аналарга баласының башкару һәм вокаль осталык дәрәҗәсен бәяләү мөмкинлеге бирелә.

**Максат:** Укучыларның белем һәм күнекмәләр комплексын мөстәкыйль куллану өчен шартлар тудыру, шулай ук балаларның танып белү мәнфәгатьләрен һәм активлыгын югары дәрәҗәдә тоту.

**Бурыч:**

Концерт эшчәнлегендә катнашу аша укучыларның иҗади сәләтләрен тормышка ашыру һәм камилләштерү мөмкинлеге;

Балаларның һәм аларның ата-аналарының эчтәлекле ял итү өчен шартлар тудыру;

Уңайлы психологик атмосфера тудыру-шатлык, уңайлык, дуслык;

Коллектив эшне башкару сыйфаты өчен җаваплылык хисе формалаштыру;

Концерт чыгышлары һәм сәхнә тәртибе тәҗрибәсен туплауга ярдәм итү.

**Концертта кулланылган төп ысуллар:** стимуллаштыру һәм мотивация.

**КОНЦЕРТ БАРЫШЫ**

Бүген, бәйрәм үткәрәбез –
Яшь талантлар кичәсен.
Иң моңлы җырчыларыбыз,
Сәләтләрен күрсәтер.
Залда утырган кунаклар,
Сез битараф булмагыз.
Көчле алкышларга күмеп,
Артистларны зурлагыз.

Хәерле кич, кадерле дуслар! Әтиләр-әниләр, әби-бабайлар, абыйлар, апалар, малайлар һәм кызлар!

Елдан-ел матур традиция булып килгән вокал бүлегенең чыгарылыш класс укучыларының концертын башлыйбыз!

Отгремела война,
Свой кровавый собрав урожай.
Сколько лет пронеслось,
Сколько новых забот пережито!

Время мчится вперед,
Время к новым спешит рубежам.
Но никто не забыт!
И навеки ничто не забыто!

**«Журавли» слова Расула Гамзатова, перевод с аварского Наума Гребнева, музыка Яна Френкеля. Исполняет Латипов Азат**

Герой рок-н-рола
На сцене стоит,
Гитара поет,
А в сердце щемит!

**На сцене Латипов Азат с песней легендарного Виктора Цоя «Звезда по имени Солнце»**

Татар җыры...

Ерак тарихлардан

Алып килә халык хәтерен.

Оялчан ул, инсаф, ягымлы ул-

Үзе салмак- үзе әкрен.

**«Безнең җыр» Рәдиф Гаташ сүзләре, Сара Садыйкова көе**

**Башкара Сабина Идиятуллина.**

Урман биргән аңа матурлыгын,
Күлләр саф суларын сипкәннәр,
Гөлләр, йоклаганда, яшрен генә
Иелеп-иелеп аны үпкәннәр;
Таң җилләре аның, исә-исә,
Озын чәчкәйләрен тараган...

**«Таң кызы» Рәмзинә Тимерова сүзләре, Мөдәрис Газетдинов көе**

«... Җырла-җырла дип әйтәсез, сезгә нинди җыр кирәк?...» дип аталган уенның кагыйдәләре белән таныштырып китим әле сезне. Мин җырларның беренче юлын укыйм,ә сез җырны танып, 1 куплетын яисә кушымтасын матур итеп җырлап күрсәтергә тиеш буласыз.

1)Без урамнан узабыз ла.....

2)Тал бөресе, тал бөресе.....

3)Бер кыз бала.....

4)Кошлар тынды урман.....

*Бик булдырдыгыз, эшли дә, ял да итә беләсез!!!*

**Концертыбызны дәвам итә Иске Карамалы кызы Лилия Ханнанова!!!**

**«Җырларым дусларыма» Гөлфия Шакирова сүзләре, Ильназ Минвалиев көе**

*Конферанс чыгышы –ТӨШ турында!!!*

**«Бибисара» Әхмәт Ерикәй сүзләре, Сара Садыйкова көе**

Җырлар белән сәфәр чыгып,

Тарих үрләреннән килгәнбез.

Татар җырын җырлап таралганбыз,

Татар җырын җырлап җиңгәнбез.

**«Җырларым» Муса Җәлил сүзләре, Салих Сәйдәшев көе.**

**Башкара Илвир Габдрахманов**

Мин хәзер дә, үзәк өзелгәндә,

Җырлар канатында тирбәләм;

Кайгы килеп, башым иелсә дә,

Сөенсәм дә, җырлап җибәрәм.

**<u>Татар халык җыры «Ай, былбылым»</u>**

Хәзер мин сезгә бер җыр турында хикәя укыйм. Сез биремне тыңлап бетерәсез, җырның исемен әйтергә, җырлап җавап бирергә тиеш буласыз. Бирем аңлашылдымы?

**1 нче текст.** Борын-борын заманда түгел, нәкъ безнең көннәрдә, бик матур җирдә бик матур кыз яшәгән. Ниндидер бер матур бәйрәм якынлашкан, кыз тырышып-тырышып нәрсәдер эшли. Шуннан соң, бик якын кешесенә нәрсәдер эшләтә. Һәм алар икәүләшеп күккә карап нәрсәдер сөйлиләр, ә бу нәрсәне алар безгә бик кирәк булган күк җисеменә сөйлиләр. Шуннан сон аларны барысы да ишетеп ала, ә инде композиторлар булып сандугачлар, тургайлар сайлана.

***Җавабы:***

*«Бер кыз бала жыр чыгарган» <u>Гөлшат Зәйнәшева</u> сүзләре <u>Фәтхерахман Әхмәдиев</u> көе*

*1)*

*Багышлап әнисенә.*
*Икәү бергә җырлыйк, диеп,*
*Өйрәткән энесенә:*

*«Кояш, кояш, мәңге балкый,*
*Мәңге нур сибә.*
*Кояш гомере телим мин,*
*Әнием, сина.»*

*2) Җырны чишмәләр ишеткән,*
*Кошлар отып алганнар.*
*Сандугачлар һәм тургайлар*
*Матур көйгә салганнар.*

Игътибар белән икенче текстны тыңлыйбыз, һәм җавап бирергә әзерләнәбез.

**2 нче текст.** Бер матур авылда,бик акыллы, яхшы күңелле хуҗа яшәгән. Аның сары төстә, тәмле әйбере булган. Бу хуҗа нигәдер аны яшереп тота торган булган. Көннәрдән бер көнне бу әйбергә хуҗалар яратмый, күрә алмый торган җан ияләре ияләшкән. Ачуы чыккан хуҗа, ышанычлы дип уйлап, мыеклы, койрыклы, ялкау җан иясен сакларга куя. Тик, каһәр суккан

ул җан иясе дә җавапсыз, алдакчы булып чыга. Хуҗаның яшереп куйган сары төстәге әйберен минут эчендә юк итә.

***Җавабы:***
*«Карак песи» <u>Муса Җәлил</u> сүзләре, <u>Җәүдәт Фәйзи</u> көе*
*1)Иртә белән майга дип*
*Керсәм, күзем акайды:*
*Явыз песи берүзе*
*Ялт иттергән ак майны!*

*— Мияу, мияу, пескәем,*
*Хыянәтче икәнсең.*
*Саклый торган маеңны*
*Үзең ашап киткәнсең!*

Бу биремне дә үтәдегез, җиңеп чыктыгыз.

**<u>Татар халык җыры «Чибәр кызга» Илһам Шакиров репертуарыннан</u>**

Кавказ кебек булмаса да,тауларың бар,
Каспий кебек булмаса да, суларың бар,
Тайга кебек булмаса да, урманың бар,
Мул уңышлар вәгъдә иткән кырларың бар,
Узеңә хас матур-матур җырларың бар.

**<u>Таҗи Гыйззәтнең «Чын мәхәббәт» пьесасынан«Әдрән диңгез» җыры Салих Сәйдәшев көе</u>**

Уйна артист, гармуныңны
Моңнар-жырга кушылсын.
Бу залда ата-аналар
Шатланып тыңлап торсын.

**<u>Татар халык җыры «Ал Зәйнәбем»</u>**

Гөл дә булыр чагыбыз,

Без җырламый, кем җырласын,

Безнең шундый чагыбыз....

**<u>Каршы алыгыз Югары Табын кызы Зилә Габдуллина</u>**

**«Теләкләр» Фәнәвис Дәүләтбаев сүзләре, Инсаф Хәбибуллин көе**

Җырсыз җирнең яме юк,

Җырсыз тормыш яме юк,

Җыр сулар һава кебек

Җыр яши, җыр – мәңгелек.

**«Белегез шуны » Илгизәр Фазлуллин сүзләре, Сара Садыйкова көе**

Җыр – кешенең гомерлек юлдашы. Татар халкы гомер-гомергә җыр белән хезмәт башкарган, җыр белән ял иткән, җыр белән ир-егетләрне яуга озаткан һәм каршы да алган, сагышланган, юанган.

**«Кайту» Марсель Галиев сүзләре, Луиза Батыр-Болгари көе**

**Башкара Булат Латипов.**

Мәхәббәт
Ул үзе иске нәрсә,
Ләкин
Һәрбер йөрәк аны яңарта,

Шигырьләргә салып елата,

Көйгә салып җырлата…

**«Ярат кына» Гөлүсә Шаһбан сүзләре, Ильназар көе**

«...Татарча да яхшы бел,

Урысча да яхшы бел...»

Ә хәзер, татар җырларының тәрҗемәләре сезгә тәкъдим ителәчәк. Сез тәрҗемәләрне дөрес танып, нинди җыр икәнен әйтергә тиеш буласыз.

**1) Не провожай меня, мой друг, не провожай,**

**Дорога длинная,может быть, я не потеряюсь.**

**Твои таинственные голубые глаза**

**Больше не на какие глаза не променяю.**

2)Вот волнуется вода,

Вот качается волна,

Под какою же звездою

Место, где ты рождена?

**3) Пришли любить мы в этот мир,**

**Сердце, которое не любит, не будет гореть,**

**Не любящее сердце – это не сердце,**

**Не горящее сердце нам не надо**

**Без любви нам никак нельзя прожить!**

4) На полях, лугах, озёрах,

Я так и не осталась, почему же не осталась?!

Каждый раз приезжая, словно обижаются,

Грустно им, очень грустно, моим ивам.

**5)Льёт и льёт дождём обильным,**

**Привязалось облако.**

**Если дали бы мне крылья,**

**Улетел б далеко.**

<u>Молодцы, булдырдыгыз татарча да, русча да бик яхшы беләсез икән.</u>

Песня, в которой есть слова «И лететь по белому свету, став одним движением ветра», называется «Лететь». Песня эта довольно - таки «старая», год выпуска ее - 1999. но не так давно ее перепел Антон Беляев для саундтрека к фильму «Лёд».

**<u>А мы с вами послушаем эту песню в исполнении Элизы Гиздатовой</u>**

Һавасы да, җире дә,
Салават күпере дә,
Яңгыры да, кары да,
Безгә якын бары да!

**<u>«Ялгыз агач » Әхмәт Саттар сүзләре, Рөстәм Яхин көе</u>**

Тибрәлгәндә генә авыл өсләрендә

Торналарның тыйнак җырлары,

Туган җирдә һәркем тыныч яшәр,

Ямьле булыр урман-кырлары.

**<u>«Кайтыгыз, торналар» Илсөяр Ганиева сүзләре, Сара Садыйкова көе Башкара Зөләйха Хантимерова</u>**

Яшәр өчен бетмәс көч алырга
Олысына һәм дә кечегә, —
Мәхәббәтле, ямьле, мәрхәмәтле
Туган ягы кирәк кешегә.

**<u>«Үз илемдә»Гөлшат Зәйнашева сүзләре, Сара Садыйкова көе.</u>**

Сизелмичә концерт үтте,

Барыбыз да бик канәгать.

Саубуллашыр вакыт җитте,

Моңсуланмыйк без, җәмәгать.

Юлларыгыз якты булсын,

Эшләрегез бары уңсын.

ОТЧЁТ  дигән концертта

Кабат очрашырга язсын

Игътибарыгыз өчен барыгызга да зур рәхмәт! Сау булыгыз!